КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.02.2026 Казан шәһәре № 83-П

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында урнашкан «Бураково шәһәрлеге II» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясенең чикләрен һәм аннан файдалануның махсус режимын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

әлеге боерыкның 1 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында урнашкан «Бураково шәһәрлеге II» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләрен;

әлеге боерыкның 2 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында урнашкан «Бураково шәһәрлеге II» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән махсус файдалану режимын.

2. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә әлеге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис вазыйфаларын башкаручы Н.В. Прохорова

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының
18.02.2026 ел, №83-П
боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында урнашкан «Бураково шәһәрлеге II» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты
**территориясе чикләре**

«Бураково шәһәрлеге II» ачыкланган мәдәни (археологик)
мирас объекты чикләренең урнашу урынына
**текстлы тасвирлама**


Объект Спас муниципаль районында, Бураково авылының төньяк-көнчыгыш читеннән 653 метр төньяк-төньяк-көнчыгышта, Көек авылының төньяк-көнбатыш читеннән 1168 метр көнбатыш-төньяк-көнбатышта, Актай елгасының уң ярындагы төп террасаның тар борынында урнашкан.

Мәдәни мирас объекты территориясе чикләре линиясе түбәндәгечә уза:

| Чик өлешләре турында белешмәләр | | |
|---|---|---|
| Чик өлешен билгеләү | | Чик өлешен узу тасвирламасы |
| ноктадан | ноктага кадәр | |
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | 2 | төньяк-көнчыгышка таба (азимут 52°01'21",62) 5,7 метр |
| 2 | 3 | төньяк-көнчыгышка таба (азимут 44°25'45",49) 5,0 метр |
| 3 | 4 | төньяк-көнчыгышка таба (азимут 44°02'16",55) 7,5 метр |
| 4 | 5 | көнчыгыш-төньяк-көнчыгышка таба (азимут 59°47'09",00) 9,4 метр |
| 5 | 6 | көнчыгыш-төньяк-көнчыгышка таба (азимут 60°03'55",81) 5,8 метр |
| 6 | 7 | көнчыгыш-көньяк-көнчыгышка таба (азимут 111°31'22",02) 8,5 метр |
| 7 | 8 | көнчыгыш-көньяк-көнчыгышка таба (азимут 113°48'57",61) 11,7 метр |
| 8 | 9 | көнчыгыш-көньяк-көнчыгышка таба (азимут 116°23'23",41) 11,1 метр |
| 9 | 10 | көнчыгыш-көньяк-көнчыгышка таба (азимут 102°52'01",57) 13,5 метр |
| 10 | 11 | көнчыгыш-көньяк-көнчыгышка таба (азимут 101°26'18",58) 17,4 метр |
| 11 | 12 | көнчыгышка таба (азимут 93°37'58",62) 12,1 метр |
| 12 | 13 | көнчыгышка таба (азимут 98°49'13",37) 7,7 метр |
| 13 | 14 | көнчыгыш-көньяк-көнчыгышка таба (азимут 112°06'33",45) |

| | | |
|---|---|---|
| | | 10,0 метр |
| 14 | 15 | көньяк-көньяк-көнчыгышка таба (азимут 166°26'48",19) 12,6 метр |
| 15 | 16 | көньякка таба (азимут 185°22'13",83) 13,0 метр |
| 16 | 17 | көньяк-көньяк-көнбатышка таба (азимут 192°12'42",90) 15,0 метр |
| 17 | 18 | көньяк-көньяк-көнбатышка таба (азимут 208°46'29",01) 14,2 метр |
| 18 | 19 | көньяк-көнбатышка таба (азимут 232°13'55",66) 11,9 метр |
| 1 | 2 | 3 |
| 19 | 20 | көнбатышка таба (азимут 261°36'27",37) 8,0 метр |
| 20 | 21 | көнбатыш-төньяк-көнбатышка таба (азимут 298°14'13",82) 14,2 метр |
| 21 | 22 | төньяк-көнбатышка таба (азимут 304°56'33",69) 15,7 метр |
| 22 | 23 | көнбатыш-төньяк-көнбатышка таба (азимут 297°52'41",49) 12,0 метр |
| 23 | 24 | көнбатыш-төньяк-көнбатышка таба (азимут 300°25'49",84) 13,1 метр |
| 24 | 25 | көнбатыш-төньяк-көнбатышка таба (азимут 294°29'54",87) 12,9 метр |
| 25 | 26 | көнбатыш-төньяк-көнбатышка таба (азимут 299°05'06",55) 14,2 метр |
| 26 | 27 | көнбатыш-төньяк-көнбатышка таба (азимут 293°35'59",95) 8,3 метр |
| 27 | 28 | көнбатыш-төньяк-көнбатышка таба (азимут 298°48'39",73) 8,8 метр |
| 28 | 29 | төньяк-көнбатышка таба (азимут 303°51'26",19) 7,8 метр |
| 29 | 1 | көнбатыш-төньяк-көнбатышка таба (азимут 296°19'40",66) 6,4 метр |

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында урнашкан «Бураково шәһәрлеге II» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты урнашу урынының **вәзгыяти планы**





Шартлы билгеләр:


- объектның урнашу урыны чиге

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында урнашкан «Бураково шәһәрлеге II» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләренең

**картасы (схемасы)**




Шартлы билгеләр:



- объект территориясе чикләренең характерлы ноктасы
- объект территориясе чиге
- биеклек билгеләре
- изолинияләр
- грунтлы кыр юлы
- үлән үсемлекләре
- урман үсемлекләре
- сирәк урман
- утыртмалар

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында урнашкан «Бураково шәһәрлеге II» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләренең характерлы
**нокталары координаталары исемлеге**

| Нокта № | Җирле координаталар системасындагы нокта координаталары (МСК-16) | | 1984 елгы Бөтендөнья геодезия координаталар системасындагы нокта координаталары (WGS-84) | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | N | E |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | 403155.32 | 1340395.25 | 55.135414 | 49.665094 |
| 2 | 403159.91 | 1340398.55 | 55.135455 | 49.665146 |
| 3 | 403164.29 | 1340400.96 | 55.135494 | 49.665185 |
| 4 | 403170.84 | 1340404.51 | 55.135553 | 49.665241 |
| 5 | 403177.60 | 1340411.04 | 55.135613 | 49.665345 |
| 6 | 403181.75 | 1340415.10 | 55.135650 | 49.665409 |
| 7 | 403176.99 | 1340422.15 | 55.135607 | 49.665519 |
| 8 | 403169.95 | 1340431.47 | 55.135543 | 49.665664 |
| 9 | 403162.79 | 1340439.89 | 55.135478 | 49.665795 |
| 10 | 403157.89 | 1340452.50 | 55.135433 | 49.665992 |
| 11 | 403152.25 | 1340468.94 | 55.135381 | 49.666249 |
| 12 | 403151.02 | 1340481.01 | 55.135369 | 49.666438 |
| 13 | 403149.09 | 1340488.42 | 55.135351 | 49.666554 |
| 14 | 403143.37 | 1340496.64 | 55.135299 | 49.666682 |
| 15 | 403130.92 | 1340498.47 | 55.135187 | 49.666709 |
| 16 | 403117.89 | 1340497.89 | 55.135070 | 49.666698 |
| 17 | 403102.95 | 1340496.17 | 55.134936 | 49.666669 |
| 18 | 403089.33 | 1340492.02 | 55.134814 | 49.666602 |
| 19 | 403079.70 | 1340485.03 | 55.134728 | 49.666491 |
| 20 | 403077.62 | 1340477.27 | 55.134710 | 49.666369 |
| 21 | 403087.21 | 1340466.85 | 55.134797 | 49.666207 |
| 22 | 403099.26 | 1340456.79 | 55.134906 | 49.666051 |
| 23 | 403107.30 | 1340447.92 | 55.134979 | 49.665913 |
| 24 | 403116.57 | 1340438.71 | 55.135063 | 49.665770 |
| 25 | 403124.50 | 1340428.56 | 55.135135 | 49.665612 |
| 26 | 403134.31 | 1340418.27 | 55.135224 | 49.665452 |
| 27 | 403139.26 | 1340411.65 | 55.135269 | 49.665349 |
| 28 | 403145.33 | 1340405.22 | 55.135324 | 49.665249 |
| 29 | 403151.18 | 1340400.13 | 55.135377 | 49.665170 |
| 1 | 403155.32 | 1340395.25 | 55.135414 | 49.665094 |

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының 18.02.2026
ел, №83-П боерыгына 2 нче
кушымта

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында урнашкан
«Бураково шәһәрлеге II» ачыкланган мәдәни (археологик)
мирас объекты территориясенең чикләрен һәм
**аннан файдалануның махсус режимы**

Чикләрендә археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус режимы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль законда (алга таба – 73-ФЗ номерлы федераль закон) билгеләнгән тәртиптә 73-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясында билгеләнгән археологик кыр эшләрен, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен һәм ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның аннан файдалана алуын тәэмин итү шарты белән башка эшләрне уздыру мөмкинлеген күздә тота.

**1. Түбәндәгеләр рөхсәт ителә:**

мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы биргән рөхсәт (ачык кәгазь) нигезендә археологик мирас объектын өйрәнү эшләрен, археологик әйберләрне эзләү һәм алу максатын күздә тоткан эшләрне дә кертеп, үткәрү;

73-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән эзләнү, проект, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен уздыру, мондый эшләрне башкару проектларында яки археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектларында, яки уздырыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган коткару археологик кыр эшләрен үткәрү планында археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән мәҗбүри бүлекләрне гамәлгә ашыру шарты белән, ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендә урманнардан файдалану һәм башка эшләр;

законнар нигезендә гражданнарның археологик мирас объектына үтеп керүен оештыру.

**2. Түбәндәгеләр тыела:**

73-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән эзләнү, проект, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен уздыру, мондый эшләрне башкару проектларында яки археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектларында, яки уздырыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган коткару археологик кыр эшләрен үткәрү планында археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән мәҗбүри бүлекләрне

гамәлгә ашырмыйча, ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендә урманнардан файдалану һәм башка эшләрне уздыру.